| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«8» апрель 2026 ел г. Альметьевск № 580

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы мәгариф
идарәсенең мәгълүмат-методика
бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте
өчен түләү шартлары турындагы»
2022 елның 16 маендагы 898 номерлы
карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы» 2022 елның 16 маендагы 898 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 26 октябрендәге 2465 номерлы, 2024 елның 3 октябрендәге 3220 номерлы, 2024 елның 27 декабрендәге 4242 номерлы, 2025 елның 23 маендагы 1122 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

2 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары | аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яисә «дипломлы белгеч» квалификациясен бирү белән расланган югары һөнәри белем бирү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 24 498,00 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 24 504,00 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркем | | | | |
| Беренче квалификация | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары; | - | - | 24 598,00 |
| | муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы); | - | - | 24 690,0 |

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтада «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)»1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.13 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| 1.13. | «Профессиягә тугрылык өчен» күкрәк билгесе |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026

елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф. Мортазинга йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М.Каюмов